**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12 нче октябрь, 2022 ел** **№ 213**

**Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Биектау муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 221 номерлы карары (23.09.2020 № 5, 12.11.2021 № 123, 31.01.2022 № 147 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) карары белән расланган тәртиптә билгеләнә торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмалары структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкыр индексларга һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарның 5 пунктындагы 5 пунктчасының икенче абзацына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «сәгать тариф ставкасының 7 проценты» сүзләрен «хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының

рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карар 2022 елның 01 октябреннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов